ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ПИСЬМЯНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ПИСМӘН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 27 октябре № 6

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлегенең Дурасово авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлегенең Дурасово авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 21 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлегенең Дурасово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Беек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, 300 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

- урамнарны яктыртуны оештыру;
-җирлекнең торак пунктлары чикләрендә авыл җирлеге юлларын ремонтлау объектларының расланган исемлеге нигезендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (юлларны карап тоту һәм ремонтлау эшләре)

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Писмән авылы, гагарин урамы, 5 йорт, Иске Писмән авылы Үзәк урам 50 йорт – авыл мәдәният йорты , 1нче адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) "Авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

«Писмән авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.В.Насретдинов